# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№2 2025 елның 26 ноябре

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урыс торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Дружбы урамындагы юлны ремонтлау (таш сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Урыс торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (сүүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)).

3. Әлеге карарны Урыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы И.С. Аксюкова